**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3284**
**28.06.2019**

Дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир участокларын һәм шәхси милектәге җир участокларын яңадан бүлү турында килешенү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.29 маддәсе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 нчы карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезнамә нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2017 елның 3 октябрендәге 5911 нче карары белән (Башкарма комитетның 2018 елның 14 августындагы 4574 нче, 2018 елның 9 ноябрендәге 6599 нчы карарлары редакциясендә) расланган Дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир участокларын һәм шәхси милектәге җир участокларын яңадан бүлү турында килешенү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.9 пунктына, 3, 4 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«3) шәхси милектәге җир участогын һәм дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир участокларын яңадан бүлү нәтиҗәсендә, шәхси милек хокукы барлыкка килә торган җир участогында дәүләт яки муниципаль милектәге, башка гражданнар яки юридик затлар милкендәге бина, корылма, төзелеше тәмамланмаган объект урнаштырылачак, урнаштыру җәмәгать сервитуты нигезендә рөхсәт ителә торган корылмадан (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылмадан) яки РФ Җир кодексының 39.36 маддәсенең 3 пункты нигезендә урнаштырылган объекттан тыш;

4) территорияне межалау проектында яки җир участогының урнашу схемасында шәхси милектәге җир участогын һәм дәүләт яки муниципаль милектәге һәм әйләнештән алынган яки әйләнеше чикләнгән җирләрне һәм (яки) җир участокларын яңадан бүлү карала, мондый яңадан бүлү территорияне РФ Җир кодексының 27 маддәсе

5 пунктының 7 пунктчасында күрсәтелгән җир участоклары белән межалау проекты нигезендә гамәлгә ашырылган очраклардан тыш; ».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карар имзаланган көннән башлап җиде көн срокта аны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин